| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Әлмәле авылы

16 декабрь 2022 ел №24/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 30.06.2021 № 10/1 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 6 нчы статьяда:**

**1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«1. Гавами тыңлауларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты халык алдында тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында бастырып чыгарылырга яки Яңа Әлмәле авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә урнаштырылган мәгълүмат стендларында шул исәптән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.drogganoye.tatarstan.ru (алга таба – бердәм портал) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба-Бердәм портал) урнаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлауларны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында бердәм порталда урнаштыру Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитеты Секретаре тарафыннан Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси кабинетыннан файдаланып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта башкарыла (алга таба - органның шәхси кабинеты) .»;

**1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«1.1. Гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, шул исәптән, кабул ителгән карарларны, нигезләүне дә кертеп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вакытлы матбугат басмасында яисә Яңа Әлмәле авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә урнаштырылган мәгълүмат стендларында бастырып чыгарыла, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла (https://www.drogganoye.tatarstan.ru) Яңа Әлмәле авыл җирлеге бүлегендә һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы " федераль дәүләт мәгълүмат системасында батырыла.».

**2) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт өстәргә:**

«4.1. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы " федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан, авторизациядән соң бердәм портал кулланып, «электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының информацион-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган бердәм идентификация һәм аутентификация системасы " федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә».

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларны һәм муниципаль норматив хокукый актның гавами тыңлауларга чыгарылган проектын бастырып чыгару датасыннан башлана һәм гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә яшәүчеләр шулай ук үзләренең фамилияләре, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туган көне һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында мәгълүмат җибәрә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Чүпрәле

муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авыл җирлеге рәсми сайтында һәм махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков